КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 август г.Казань № 761

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советын оештыру турында» 2018 ел, 19 апрель, 269 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 676 нчы; 2020 ел, 17 февраль, 117 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 820 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Координация советы составыннан А.А.Кәримовны чыгарырга;

Яраштыру комитеты составына Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары Олег Владимирович Коробченконы кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 август, 1613-б номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 21 февраль, 280-б номерлы, 2017 ел 15 июнь, 1299-б номерлы, 2020 ел, 28 май, 1049-б номерлы, 2021 ел, 16 август, 1534-б номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларының торышын тикшереп тору буенча оператив штаб составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оператив штаб составыннан А.А.Кәримовны, Р.Р.Сафиулинны чыгарырга;

оператив штаб составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Коробченко Олег Владимировичны | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын, оператив штаб җитәкчесе урынбасарын |
| Сәлахов Ленар Айдар улын | «Камский бекон» ҖЧҖ генераль директорын (килешү буенча). |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 август, 2157-б номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 сентябрь, 2267-б номерлы; 2018 ел, 12 февраль, 240-б номерлы; 2019 ел, 29 август, 2127-б номерлы; 2020 ел, 27 гыйнвар, 122-б номерлы, 2021 ел, 27 ноябрь, 2459-б номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының ваклап сату өлкәсендә конкурентлылыкны арттыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

эшче төркем составыннан А.А.Кәримовны чыгарырга;

эшчн төркем составына Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын, ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасары Олег Владимирович Коробченконы кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин